**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОКАКЕРЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**Улица Советская, дом 51,**
**село Старые Какерли, 422476**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ районы ИСКЕ КӘКЕРЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**Совет урамы, 5**
**51нче йорт,**
**Иске Кәкерле авылы, 422476**

**Тел.: (84375) 3-01-35, факс: (84375) 3-02-35, e-mail: Skaker.Drz@tatar.ru,**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

6 июль 2020 ел № 15

Йорт хайваннарын урамда йөртү өчен урыннар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль Закон, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 ел, № 489-ФЗ Федераль закон, авыл җирлеге Уставы нигезендә, Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын урамда йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

-хуҗасы милкендә яки кулланышта булган җир кишәрлекләре;

- Борынчыкларда һәм хуҗалары күзәтүе астында кешеләр күпләп җыелмаган авыл җирлеге территориясендәге буш урыннар, торак сектор артында урнашкан урыннар:

1) Иске Кәкерле авылының көньяк өлешендә Колхоз урамыннан 50 метр;

2) Иске Кәкерле авылының көнчыгыш өлешендә Тау урамыннан 50 метр;

3) Иске Кәкерле авылының төньяк өлешендә Кул, Совет урамыннарыннан 50 метр 4) Иске Кәкерле авылының көнбатыш өлешендә Удил урамыннан 50метр

5) Татар Төкесе авылынң төньяк өлешендә Урман урамыннарыннан 50 метр

6) Татар Төкесе авылынң көнчыгыш өлешендә Мәктәп урамыннарыннан 50 метр ераклыкта.

2. Балалар һәм спорт мәйданчыкларында, парклар, скверлар, массакүләм ял итү урыннарында, балаларга белем бирү һәм дәвалау учреждениеләрендә, мәдәният объектларына якын территорияләрдә, кибетләрдә, хайваннар белән бергә бару өчен махсус объектлардан тыш, йорт хайваннарын ирекле йөртүне тыярга.

Әлеге пунктның гамәлдә булуы поводырь этләренә кагылмый.

3. Җирле үзидарә органы карары белән хайваннарны урамда йөртү өчен рөхсәт ителгән урыннардан читтә йөртүгә, юл куймаска.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Иске Кәкерле авыл җирлеге
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы: Н.Л.Исхаков